■ Сез моны белергә тиеш

# БИШ ТӨРЛЕ ФАРЫЗ

Безнең өстебезгә биш төрле фарыз йөкләнә. Беренчесе - иманны яхшы белү, икенчесе - биш вакыт намаз, өченчесе - зәкят, дүртенчесе ураза, бишенчесе - көче җиткән кешегә хаҗ. Әгәр динебезгә ниндидер тарафтан куркыныч янаса, шул вакытта динебезне яклап, көрәшкә чыгу - җиһад дип атала. Бу - безнең бурычыбыз, ягъни алтынчы фарыз шикелле. Без моннан тайчансак, без моннан читтә калсак, без гөнаһ эшләгән кешеләр булабыз. Үзебезне мөселман диеп санайбыз икән, без Аллаһ Тәгаләгә, Пәйгамбәребезгә тел-теш тидергән кешеләргә каршы чыгарга тиешбез. Чөнки бу - Ислам диненә янаган куркыныч. Инде каршы чыгарга көч табалмыйбыз икән, аңа йөрәгебез җитми икән, без бу дин дошманнарын ташлап китәргә, алар янында тормаска тиеш. Динебезгә афәт янамаган вакытта дингә өндәү - безнең бурычыбыз. Бүгенге көндә, Аллаһка шөкер, корал тотып динне яклау ихтыяҗы юк. Дингә өндәү бүгенге көндә безнең алтынчы фарызыбыз, бурычыбыз булып тора. Бу эш иң элек үз гаиләңнән башлансын, үзеңнән, хатыныңнан, балаларыңнан. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм әйтте: сезнең хәерлегез шул кешедер ки, ул үзенең өйрәнгәнен икенче кешеләргә җиткерә, - диде. Коръәни Кәримдә дә аять бар:

("Фуссыйләт", 33) "Аллаһ Тәгаләнең сүзен кешеләргә җиткерүче кешедән дә күркәмрәк кешеләр булмас", - диелә. Менә монысы - Аллаһ тәгалә сүзе, Ул үзе әйтә: "Миңа сүземне кешеләргә җиткерүчеләрдән дә якынрак кеше булмас". Пакыстаннан үзләренең җылы өйләрен, гаиләләрен, байлыкларын калдырып, шушында килгән кешеләр - алар алтынчы вазифаларын, алтынчы бурычларын үтәргә дип чыккан кешеләр. Араларында төрле һөнәр кешеләре бар: укытучылар, врачлар, экономистлар. Алар, үз хисапларына, бер-ике ай ял алып, безне дингә өндәргә, Аллаһ юлына чакырырга чыкканнар, һәм без болардан куркып, шикләнеп калырга тиеш түгел. Аларны ачык йөз белән каршы алырга кирәк. Аларның әйткәннәрен, вәгазьләрен тыңларга кирәк. Күпләребез, җомга көнне, җылы өеннән чыгып, мәчеткә килергә үзендә көч табалмый. Килә алмавына 40 төрле сылтау таба: аңа йә мулласы, йә мәчеткә йөргән кеше ошамый. Сиңа мәчеткә йөргән кешенең ошавы нигә кирәк? Аллаһка иман китергән икән, шушы иманы аны мәчеткә чакырырга, мәчеткә китерергә тиеш. Монда ул Аллаһ Тәгалә каршында булган фарызын үти. Аның монда килеп фарызын үтәве беребез өчен дә түгел, Аллаһ тәгалә өчен дә түгел, бары тик үзе өчен генә. Аллаһ тәгалә әйтә:

"Кылган яхшылыкларыгыз, яхшылык кылсагыз, үзегез өчендер, начарлык кылсагыз да, аның зарарын фәкать үзегез генә күрерсез, - ди. (17:7).

Без нәрсәдер эшлибез икән: садака бирәбезме, Коръән укыйбызмы, мәчеткә барабызмы, моның файдасчы фәкать үзебез өчен генә. Аллаһ Тәгалә безнең намазыбызга да, биргән садакабызга да. чалган корбаныбызга да мохтаҗ түгел. Бу эшләгән эшләребез - үзебез өчен, ахирәтебез өчен, балаларыбызның киләчәге өчен. Бер риваять бар. Берәү сорый Аллаһ Тәгаләдән: "Үзеңең каршыңдагы иң ямьсез кешене миңа күрсәт әле", - дип. Аллаһ тәгалә әйтә: "Әнә, кара әле", - ди. Караса, урамда, пычракта бер кеше исереп, аунап ята. "Минем каршымда шушыннан да күңелсез кеше юк", - ди Аллаһ Тәгалә. Икенче көнне теге кеше әйтте Аллаһ Тәгаләгә: "Син, - диде, - миңа каршыңдагы иң якын кешене күрсәт", - диде. Аллаһ тәгалә әйтә: "Әнә, кырга чык та кара!" - ди. Анда исә бер адәм баласына табигатьне күрсәтеп йөри. Кырдагы чәчәкләрне, хуш исләрне, агачларны, матурлыкны, җирләрне, күкләрне. Үзе: "Менә боларның барысын да Аллаһ Тәгалә яраткан, балам, боларның барысының да хуҗасы - Аллаһ тәгалә. Без барыбыз да Аллаһка гыйбадәт кылырга тиеш", - ди. Аллаһ Тәгалә әйтте: "Мине зурларга өйрәткән кешедән дә якынрак кеше юк", - диде.

Кайвакыт улыбызга, йә булмаса, күршебезгә: "әйдә, мәчеткә барыйк, шушы эшне эшлик әле", - дигәч, ул безгә бер кире сүз әйтсә, бөтен дөньябыз җимерелгәндәй була. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.), берәүне дингә керергә өндәп, аңа 100 мәртәбә мөрәҗәгать итте. сәхабәләр: "Йә, Расүлуллаһ, инде бу кешедән өмет өзеп, кул селтәгәнсендер", - диделәр. Пәйгамбәребез: "Нишләп өмет өзим, бәлки аның күңеленә һидаят 101 нчесендә керер", - диде.

Без кайвакыт күршебезне яки танышыбызны: "Әйдә, җомгага кил әле", - дип чакырабыз да, ул безне сүгеп ташласа, безнең өчен шуның белән эш бетә, тукталып калабыз.

Үзебез күпмедер хаклыкны күргәнбез, хак юлга кергәнбез икән, башкаларны да шушы юлга өндик, чөнки үлем хак булган шикелле, кыямәт көне дә хак. Тәмугтагы танышларыбыз безгә: "Үзең барганда ник мине дә мәчеткә чакырмадың, үзең хак юлны тапкач, ник мине дә өндәмәдең?" - дип, безгә үпкә белдерәчәк. Йә булмаса, без үзебез, ниндидер начарлыкка иярсәк, шул кешегә үпкә белдерәчәкбез. Шуңа күрә бу дөньяда, әле мөмкинлегебез барында, хак юлны табыйк һәм башкаларны да шушы юлга өндик. Әйткәнемчә, бер яхшылыкның йөз яхшылык булып языла торган ае.

**Җәлил хәзрәт ФАЗЛЫЕВ**
***вәгазьләреннән алынды.***

■ Иманга юл

# ИЗГЕ ГАМӘЛЛӘРНЕҢ САВАБЫ

Шамил хәзрәт ГАЛӘВЕТДИН

***Ураза тота торган ай ни өчен "Рамазан" дип атала?*** Абдулла.

Рамазан - ялгызлык исем, Ай календаренда ураза тотыла торган тугызынчы айны белдергәнгә күрә шулай аталган.

Бер хәдистә ураза тотучы өчен берничә файдалы тәкъдим бар. "Уразаны тотучы кешегә көч бирүдә кулланыла торган 3 тәҗрибә бар: 1) башта ашарга, аннары эчәргә кирәк (ашаганда күп эчмәскә, ашказаны согын сыеклатмаска, ризык кулланып, 40-60 минут узгач кына эчәргә), 2) сәхәр вакытында азыкны куллану, 3) көндез йоклап алырга (13:00 сәгать белән 16:00 арасында 20-40 минут һәм аннан күбрәк черем итергә)".

Бу хәдиснең сөннәткә туры килгән беренче пунктының асылы шуннан гыйбарәт: кеше мәсәлән, кичке авыз ачу вакытында беренче эш итеп су эчә һәм берничә хөрмә ашый. Аннары кичке намазны укый, соңрак ашый. Беренче итеп су эчү ашказаны-эчәкләрне юдырырга ярдәм итә. Сүз уңаеннан, ач карынга җылы су эчү файдалы. Аңа бераз бал да кушып җибәрсәгез була. Хәдистә ифтар вакытында ризык кабул иткәч, аны сыеклату белән мавыгырга тәкъдим ителми. Бер үк вакытта күп итеп ашау һәм эчү нәтиҗәсендә ашказанында ризыкны эшкәртү кыенлаша (ашказаны согы сыеклана), бу исә ризыкның эшкәртелеп бетмәвенә китерә, сару кайный башлый. Ураза вакытында бу кайбер кынелыклар китереп чыгара: кичтән кабул ителгән ризык эшкәртелеп бетми, иртәнге якта кеше йә бөтенләй ашамый, чөнки ачыкмаган була, ашаса инде ризык өстенә кабул иткән булып чыга. Ә бу исә көтелгән нәтиҗәгә китерми.

Мөселманнар кич белән һәм иртәнге якта, ягъни авыз ачканда, сәхәр вакытында артык ризык кулланудан саклансыннар иде. Кызганыч ки, иманнары ныгып җитмәгән кайберәүләр ачлыктан куркып, калып, күп ризык ашыйлар. Бу аларга көн дәвамында күтәренке кәефне сакларга булышыр, дип уйлап ялгышалар. Организмына күп ризык керткән кеше үзе өчен гадәти булмаган, кыен хәлдә кала: бихисал авыр ризыкны эшкәртү өчен аның бөтен көндез тупланган энергиясе китә, шуңа күрә икенче көнне андый затлар йокылыуяулы, арган кыяфәтле, "Аллаһ ризалыгы хакына үз-үзен интектерүче"гә әйләнә. Күпләр шулай эшли һәм бу Раббыбыз нигъмәтләреннән дөрес файдаланмау булып тора.

Мик кич белән салатларга, җиләк-җимеш, яшелчәләргә басым ясарга, ә иртән ботка, кимкән җимеш һәм чикләвекләр ашарга киңәш итәр идем.

кеше үзгәрә һәм һәр көнне тоткан уразасы аны үзгәртә. Әгәр ул үзенә җитәрлек дәрәҗәдә генә көненә ике тапкыр ризык кулланса, суны шулай ук җитәрлек дәрәҗәдә эчсә, 7 сәгатьтән дә кимрәк, 8 сәгатьтән дә күбрәк йокламаса, физик күнегүләр ясарга иренмәсә (5-6 чакрымны җәяү йөрсә, йөзү белән шөгыльләнсә, җиңелчә йөгерсә), аның тоткан уразалары файдага булыр дип уйлыйм. Бередә иң мөһиме - уразаны Аллаһ ризалыгы өчен дип тоту.

***Ураза тотучы кеше төнге сменада эшли, ә көндезен йоклап уздыра. Ул Аллаһ тарафыннан көндезләрен актив үткәргән кеше кебек үк бүләк алачакмы?*** Лена

Әгәр аның эш графигы шундый икән, әлбәттә, ул шундый ук бүләк алыр. Шунысын исегезгә төшерәм: тәүлегенә 8 сәгатьтән артык, 7 сәгатьтән ким йоклау зыянлы.

## Өфөлә намаҙ ваҡыты

**Рамаҙан-Шәүүәл 2013 миләди йыл**
**1434 һижри йыл.**

| Рамаҙан, Шәүүәл | Аҙна көндәре | Июнь, Июль | Иртәнге намаҙ | Ҡояш сыға | Өйлә нам. | Икен. нам. | Аҡшам. | Йәстү намаҙы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 8 | Шишәмбе | 16 | 4.02 | 4.32 | 14.30 | 21.11 | 22.41 | 00.11 |
| 9 | Шаршамбы | 17 | 4.04 | 4.34 | 14.30 | 21.09 | 22.39 | 00.09 |
| 10 | Кесе йома | 18 | 4.05 | 4.35 | 14.30 | 21.08 | 22.38 | 00.08 |
| 11 | Йома | 19 | 4.07 | 4.37 | 14.30 | 21.17 | 22.37 | 00.07 |
| 12 | Шәмбе | 20 | 4.08 | 4.38 | 14.30 | 21.15 | 22.35 | 00.05 |
| 13 | Йәкшәмбе | 21 | 4.10 | 4.40 | 14.30 | 21.04 | 22.34 | 00.04 |
| 14 | Дүшәмбе | 22 | 4.11 | 4.41 | 14.30 | 21.02 | 22.32 | 00.02 |
| 15 | Шишәмбе | 23 | 4.13 | 4.43 | 14.30 | 21.01 | 22.31 | 00.01 |
| 16 | Шаршамбы | 24 | 4.14 | 4.44 | 14.30 | 20.59 | 22.29 | 23.59 |
| 17 | Кесе йома | 25 | 4.16 | 4.46 | 14.30 | 20.58 | 22.28 | 23.58 |
| 18 | Йома | 26 | 4.18 | 4.48 | 14.30 | 20.56 | 22.26 | 23.56 |
| 19 | Шәмбе | 27 | 4.19 | 4.49 | 14.30 | 20.54 | 22.24 | 23.54 |
| 20 | Йәкшәмбе | 28 | 4.21 | 4.51 | 14.30 | 20.53 | 22.23 | 23.53 |
| 21 | Дүшәмбе | 29 | 4.23 | 4.53 | 14.30 | 20.51 | 22.21 | 23.51 |
| 22 | Шишәмбе | 30 | 4.24 | 4.54 | 14.30 | 20.49 | 22.19 | 23.49 |
| 23 | Шаршамбы | 31 | 4.26 | 4.56 | 14.30 | 20.47 | 22.17 | 23.47 |
| 24 | Кесе йома | 1 | 4.28 | 4.58 | 14.30 | 20.45 | 22.15 | 23.45 |
| 25 | Йома | 2 | 4.30 | 5.00 | 14.30 | 20.43 | 22.13 | 23.43 |
| 26 | Шәмбе | 3 | 4.31 | 5.01 | 14.30 | 20.41 | 22.11 | 23.41 |
| 27 | Йәкшәмбе | 4 | 4.33 | 5.03 | 14.30 | 20.40 | 22.10 | 23.40 |
| 28 | Дүшәмбе | 5 | 4.35 | 5.05 | 14.30 | 20.38 | 22.08 | 23.38 |
| 29 | Шишәмбе | 6 | 4.37 | 5.07 | 14.30 | 20.36 | 22.06 | 23.36 |
| 30 | Шаршамбы | 7 | 4.38 | 5.08 | 14.30 | 20.33 | 22.03 | 23.33 |
| 1 | Кесе йома | 8 | 5.10 | 6.40 | 14.30 | 20.31 | 22.01 | 23.31 |
| 2 | Йома | 9 | 5.12 | 6.42 | 14.30 | 20.29 | 21.59 | 23.29 |
| 3 | Шәмбе | 10 | 5.14 | 6.44 | 14.30 | 20.27 | 21.57 | 23.27 |
| 4 | Йәкшәмбе | 11 | 5.16 | 6.46 | 14.30 | 20.25 | 21.55 | 23.25 |
| 5 | Дүшәмбе | 12 | 5.18 | 6.48 | 14.30 | 20.23 | 21.53 | 23.23 |
| 6 | Шишәмбе | 13 | 5.19 | 6.49 | 14.30 | 20.21 | 21.51 | 23.21 |
| 7 | Шаршамбы | 14 | 5.21 | 6.51 | 14.30 | 20.19 | 21.49 | 23.19 |
| 8 | Кесе йома | 15 | 5.23 | 6.53 | 14.30 | 20.16 | 21.46 | 23.16 |

# ҮГЕТ-НӘСЫЙХӘТ

## Догалар нигә кабул булмый икән? (риваять)

*Рухи остаз, Ибраһим ибн Әдһәм Басра шәһәренең урамнарыннан барган вакытта Басрада яшәүче кешеләр җыелып, хәзрәттән:*

- Әй, хәзрәт, Аллаһы Тәгалә Үзенең китабында әйткән:

"Сез Миннән сорагыз, Мин догаларыгызга җавап кайтарырмын", - дип. Ни булда икән безгә? Без Аллаһы Тәгаләдән сорыйбыз, әмма ул безгә җавап кайтармый. Нигә догаларыбыз кабул булмый икән? - дип сорадылар.

- Әй, Басра шәһәрендә яшәүче кешеләр, ничек Аллаһы Тәгалә догаларыгызга җавап бирсен? Сезнең күңелләрегез, йөрәкләрегез үле бит. Күңелләрегезнең, йөрәкләрегезнең үлүендә ун төрле сәбәп бар. Беренчесе, без Аллаһы Тәгаләгә иман китердек, аны таныдык, дип әйтәсез, Коръәнне бик матур итеп укыйсыз, әммә Коръән өйрәткәнчә эшләмисез. Аллаһының илчесе, Мөхәммәтне (с.г.с.) сөябез, хөрмәт итәбез, дип әйтәсез, әмма ул күрсәткән юлдан читләшеп йөрисез. Шайтан - безнең дошманыбыз, дип сөйлисез, әмма эшләгән эшләрегезгә карасаң, аны үзегез дус иткәнсез. Җәннәткә керергә телибез, дип аңлатмалар бирәсез, әмма анда эләгер өчен бернинди тырышлык куймыйсыз. Җәһәннәм утыннан котылырга кирәк, дип кычкырасыз, әмма үзегез анда илтә торган юлларда йөрисез. Үлем тиздән килер, безне алып китер, дип сөйләгән буласыз, әмма ул үлемгә бер дә әзерлек күрсәтмисез. Кешеләрне тикшереп гомерегезне уздырасыз, әмма үзегезнең кимчелекләр чокырына төшеп батканыгызны сизмисез. Сезнең арагызда үлгән кешеләрне, кабергә илтеп, күмеп куясыз, әмма шуннан гыйбарәт ала белмисез. Аллаһы Тәгаләнең нигъмәтләрен иртә, кич ашап торасыз, бар өстенә "юк", дип Аллаһы Тәгаләгә рәхмәт әйтә белмисез. Әй, Басрада яшәүче кешеләр, сез бит тере булып күренсәгез дә, анда-монда селкенеп йөрсәгез дә, Аллаһы Тәгалә каршысында мәетләр кебек яшисез. Мәетләр Аллаһы Тәгаләдән нәрсә сорый алсыннар? Берәр әйбер сорасалар да, Аллаһы Тәгалә мәетләргә ничек җавап бирсен!? Догагызның кабул булуны теләсәгез, күңелләрегезне терелтеп, мәет булудан үзегезне коткарыгыз, - диде.

*Хөрмәтле дустым, пәйгамбәребез (с.г.с.):*

"Дога кылу - гыйбадәтнең җилеге (уртасы, тамыры, нигезе)" - дип әйткән. Аллаһы тәгаләне танып, Аннан сорамыйча, дога кылмыйча яшәгән бәндә бик тирән гафләт йокысында гомер кичерә, дигән сүз. Догасыз яшәгән кеше үзенең кем икәнлеген, дөньяга ни өчен киләгәнлеген һәм тиздән кая барачагын белмичә яши. Догасыз яшәгән кеше, никадәр күкрәк киереп: "Мин бәхетле", дип әйтсә дә, ул бәхетсезләрнең иң бәхетсезе. Һәм аның бәхетсез булуын бик тиз күреп була. Дога кылу, Аллаһыга ышану, Аны тану һәм Аңардан гына сорау "дару"ына кешенең сәламәтлеге, тынычлыгы һәм бәхете салынган. Дога чишмәсеннән авыз итмәгән кеше үзен һәм башкаларны "мин бәхетле", дип ялганламасын. Доганың кабул булуы һәм кабул булмавы ул кадәр әһәмиятле түгел, иң мөһиме - догалы булып яшәүдә. Чөнки күп вакытта кеше Аллаһыдан нәрсәдер сораган була һәм шул соравының нәтиҗәсен күрмичә, кабул булмавын күреп, бик кайгыра. Коръәндә әйтелгән, пәйгамбәребезнең (с.г.с.) сөннәтендә урын алган шундый сүзләр бар. Ул да булса: "Әгәр дә кешенең сораган соравы аның өчен хәерле булмаса, кабул булмыйча, хәерлерәк бер әйбер белән алмаштырыла". Шуңа күрә кеше догалы булып яшәргә тиеш. Сораган теләкләре нинди генә рәвештә кабул булса да, ул кабул булган, дигән сүз. Бер сүз белән әйткәндә, дога төшенчәсенә Аллаһтан сорау, Аллаһка ышану һәм Аллаһка таяну, һәр эшнең нәтиҗәсе - Аллаһы тәгаләдән, дигән мәгънә салынган.

Әй, сөекле дустым! "Догам кабул булсын" дисәң, һәр хәлендә Аллаһы Тәгаләгә нык инан һәм таян. Ул тыйганнардан тыел, кушканнарын үтәргә тырыш. Ашаган ризыгың, кигән киемең, яшәгән йортың хәләлдән булсын. Догаң кабул булсын, дисәң, кешеләрне кулың белән, телең белән, хаксыз рәвештә аларның малларын үзләштерүең белән рәнҗетмә. Догаң кабул булсын, дисәң, күңелең сабыйлар кебек булсын. Ашыйсы килгән сабый, сүз әйтмичә, елап, әнисен чакырган кебек, син дә кайвакыт сүз әйтмичә, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтен өмет итеп, елый бел.

***"Бәхетлеләрнең серләре" китабыннан алынды.***